| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>10 июля 2015 года | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>№547 |

Зеленодольск муниципаль район Советы 2014 елның 05 ноябрендәге 461 номерлы Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар» ның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре нигезләмәсен раслау турында» гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2014 елның 22 декабрендәге 431 номерлы «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 23 мартындагы УП 308 номерлы «Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» Указын исәпкә алып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1.Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында» 2014 елның 05 ноябрендәге 461 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның

керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында», шулай ук «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы нигезләмәне раслау турында»гы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 пунктның «в» пунктчасында:

1.1) «әгәр алыш-биреш суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш кылуга кадәрге өч ел эчендә гомуми кеременнән артып китсә» сүзләрен «әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч ел эчендә гомуми кеременнән артып китсә» сүзләренә алмаштырырга;

1.2) «алыш-биреш башкарылган» сүзләрен «бу алыш-бирешләр башкарылган» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктта:

2.1)"алыш-биреш башкарылган" сүзләрен “алыш-бирешләр ясалган (алыш-биреш ясалган)” сүзләренә алмаштырырга;

2.2) «әгәр алыш-биреш суммасы муниципаль вазыйфаны биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш кылуга кадәрге өч ел эчендә гомуми кеременнән артып китсә» сүзләрен «әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы муниципаль вазыйфаны биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч ел эчендә гомуми кеременнән артып китсә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**

**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**